**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында**

**БӘЯЛӘМӘ**

2022 елның «27» сентябре Олы Кайбыч ав.

**Гавами тыңлаулар уздыру урыны һәм вакыты:**
2022 елның 27 сентябре 10 сәг 00 минутта, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы Бульвар, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Кайбыч авыл җирлеге административ бинасы.

**Гавами тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә:**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышу.

**Гавами тыңлаулар уздыру нигезе:** «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында» 2022 елның 25 августындагы 379 номерлы Башкарма комитеты карары.

**Гавами тыңлауларны оештыручы:** Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба - Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре) буенча гавами тыңлауларда катнашучылар саны: 11 кеше.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча буенча ачык тыңлауларда катнашучы һәм территориядә даими яшәүче гражданнардан тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителмәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын карау буенча 2022 елның 27 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә әзерләнде.

**Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗәләр:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын раслау турында карар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

2. Гавами беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советына карар кабул итү өчен җибәрергә.

3. Әлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори») челтәр басмасында, Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районының http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга (халыкка таратырга).

Гавами тыңлаулар рәисе: ____________________ /А.Н.Макаров/

Гавами тыңлаулар секретаре: __________________ /Ю.В.Гайнуллина/